Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль район Советының бишенче утырышы

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

9 декабрь, 2020 ел № 36

2014-2020 елларга Татарстан Республикасында дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча чаралар программасын үтәү нәтиҗәләре турында

Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарының «2014-2020 елларга Питрәч муниципаль районында Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча чаралар программасын үтәү нәтиҗәләре турында» гы (алга таба - Программа) докладын тыңлаганнан соң **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карар кабул итте:**

1. Программаны үтәү йомгаклары турындагы мәгълүматны игътибарга алырга.

2. Түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

2.1. Питрәч муниципаль районы башкарма комитетына:

- Татарстан Республикасының дәүләт телләре буларак татар һәм рус телләренең оптималь эшчәнлеген тәэмин итү эшен көчәйтергә;
- «2021-2025 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» муниципаль программасы чараларын нәтиҗәле үтәү эшен оештырырга;

2.2. Питрәч муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф бүлегенә:

- укучыларның тел һәм сөйләм мәдәниятен саклау һәм үстерү чараларын көчәйтергә;
- олимпиадаларда һәм конкурсларда катнашып, сәләтле балалар белән эшләүне дәвам итәргә;
- рус һәм татар телләре укытучыларының педагогик әзерлеген һәм осталыгын арттырырга (укыту семинарлары, һөнәри конкурслар уздырырга);

2.3. Районның предприятиеләренә, учреждениеләренә һәм оешмаларына, милек рәвешләренә бәйсез рәвештә, «Татарстан Республикасының дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында» Татарстан Республикасы Законын үтәү буенча кирәкле чаралар күрергә.

3. Әлеге карарны Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Питрәч муниципаль районы Советының социаль мәсьәләләр, сәламәтлек саклау, мәгариф, мәдәният һәм яшьләр эшләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Питрәч муниципаль районы башлыгы И.М. Кашапов

СОВЕТ ПЕСТРЕЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА